ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Мира, д.11А,пос.с-за "Мамадышский",
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422165

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ТАУ АВЫЛЫ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Мира ур., 11А нче йорт, "Мамадыш" совхозы
поселогы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422165

тел.(факс): (85563) 3-91-14; e-mail: KrGor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление Карар

"29" января 2024 г. № 6

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегендә җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында**

«Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 нче гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль законның 9 статьясының 3 пункты һәм 12 статьясының 3 пункты (үзгәрешләр һәм өстәмәләрне исәпкә алып), «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Башкарма карар бирә:

1. Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 8370,2 сум күләмендә билгеләргә һәм 2024 нче елның 1 февраленнән 1 нче һәм 2 нче Кушымталар нигезендә гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 30 январендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында» №5 карарын гамәлдән чыкты дип танырга.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында («Нократ ("Вятка")) бастырып чыгагрырга һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында (http://mamadysh.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче /В.А.Гиззатуллина/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл жирлеге
Башкарма комитетының
29.01.2024 ел , № 6 карарына
1 нче № кушымта

2024 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле үлгән (һәлак булган) очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен документлар әзерләү | 0 |
| 2. Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 3850,33 |
| 3. Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 1003,26 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3516,61 |
| Барлыгы | 8370,2 |

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге
Башкарма комитетының
29.01.2024 ел , № 6 карарына
2 нче № кушымта

2024 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә, тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. 1.Җирләү өчен документлар әзерләү | 0 |
| 2. Мәетне киендерү, кәфенләү | 1194,54 |
| 3.Гүргә индерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 2765,12 |
| 4.Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 1023,57 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3386,97 |
| Барлыгы | 8370,2 |